**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИЖЕВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**К А Р А Р**

30.03.2026 ел № 16

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлеге Советының "Физик затлар мөлкәтенә салым турында" 2024 елның 17 июнендәге 131 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәсенең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 28 ноябрендәге 425-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлеге Советының "Физик затлар мөлкәтенә салым турында" 2024 елның 17 июнендәге 131 нче номерлы карарына (алга таба-Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә

1.1. Карарның 2 пункты 2.4 пунктчасындагы 4 абзацны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

»- һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган салым салу объектлары, проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төзелеп бетмәгән объектлардан тыш".

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән, әмма әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән кимендә бер айдан да иртәрәк булмаган срокта үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://mendeleevsk.tatarstan.ru « Ижевка авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлеге Советының Финанс-бюджет мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Ижевка авыл җирлеге Советы рәисе Р.Т.Мәсәгутова